КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 март г.Казань № 125

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты кысаларында пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру чараларын гамәлгә ашыру турында

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты кысаларында пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты кысаларында пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру чараларын гамәлгә ашыру буенча төбәк координаторы итеп Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру чаралары карала торган «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты составына керә торган «Үз илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллау» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирелә торган чаралар (нәтиҗәләр) исемлеген;

пилотсыз авиация системаларын әзерләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү процессларын гамәлгә ашыру өчен махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) һәм практик әзерләү үзәкләрен булдыру планлаштырыла торган мәгариф оешмаларын сайлап алуны нигезләүне;

2024 елда пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру буенча чаралар комплексын («юл картасын»);

2024 елда пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен инфраструктурасын җиһазлар белән җиһазландыру планлаштырыла торган төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары исемлеген;

төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазландыру чараларын башкару нәтиҗәлелегенең максатчан күрсәткечләрен.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 март, 125 нче
карары белән расланды

Пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру чаралары карала торган «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проекты составына керә торган «Үз илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллау» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирелә торган чаралар (нәтиҗәләр) исемлеге

| Т/с | Бюджет классификаторы буенча чара (нәтиҗә) коды | Чара (нәтиҗә) исеме | Үлчәү бердәмлеге (үлчәү берәмлекләренең гомумроссия классификаторы буенча) | База күрсәткече | | Программаны гамәлгә ашыру еллары буенча чара (нәтиҗә) күрсәткече | Чарага (нәтиҗәгә) ирешү датасы | Чара (нәтиҗә) төре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | күрсәткече | елы | 2024 год | | |
| 1. | 2030 елга кадәр чорга пилотсыз авиация системаларына дәүләт граждан заказын гамәлгә ашыру тәэмин ителде | | | | | | | |
| 1.1. | 50470 | Пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын амәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җиһазлар белән җиһазландырылды | үлчәү | 0 | 2023 | 19 | 31.12.2024 | товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 март, 125 нче
карары белән расланды

Пилотсыз авиация системаларын әзерләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү процессларын гамәлгә ашыру өчен махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) һәм практик әзерләү үзәкләрен булдыру планлаштырыла торган мәгариф оешмаларын сайлап алуны нигезләү

Хәзерге вакытта пилотсыз авиация системалары эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә (аэрофотога төшерү, күзәтү, махсус билгеләнешләр һ.б.) актив кулланыла.

Татарстан Республикасында пилотсыз очу аппаратлары җитештерүче предприятиеләрнең күпчелек өлеше махсус билгеләнештәге продукция чыгара, әмма «Пилотсыз авиация системалары» дигән яңа илкүләм проектын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, предприятиеләр үз юнәлешен гражданлык ихтыяҗларына үзгәртергә тырыша. Шулай ук әлеге тармакта эш алып баручы яңа компанияләр дә барлыкка килә.

2023 елда Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча Хөкүмәт ведомствоара комиссиясе төзелде, «Татарстан Республикасы Дроннар (пилотсыз һава суднолары) узышы федерациясе» төбәк физкультура-спорт иҗтимагый оешмасы теркәлде, ул республика ярышларын оештыру һәм командаларны бөтенроссия һәм халыкара ярышларга әзерләү белән шөгыльләнә.

Якын арада Иннополис шәһәрендә шәһәр мохитендә дроннар очышы өчен илдә беренче махсус хокукый режим барлыкка киләчәк. Татарстан Республикасы буенча агродроннар өчен эксперименталь хокукый режим гамәлдә инде, ул басуларда легаль рәвештә очарга һәм аларга сиптерергә мөмкинлек бирә.

2024 елда Татарстан Республикасында «Үз илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллау» федераль проекты кысаларында ике шәһәр округының һәм биш муниципаль районның 18 гомуми белем бирү оешмасы базасында махсуслаштырылган класслар (түгәрәкләр), шулай ук «Лаеш техник-икътисадый техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү процессларын гамәлгә ашыру өчен гамәли әзерләү үзәген булдыру планлаштырыла. Әлеге барлык мәгариф оешмаларында проектны гамәлгә ашыру өчен квалификацияле педагогик кадрлар бар; бүлмәләр санитария нормаларына һәм янгынга каршы куркынычсызлык нормаларына туры килә.

Татарстан Республикасында профильле мәктәпләрнең төрле модельләре эшли. Моңа «Инженерлык республикасы» мәгариф проекты мисал булырга мөмкин; аның төп идеясе – һөнәри инженерлык-техник эшчәнлеккә мотивлаштырылган талантлы балаларны ачыклау һәм укыту максаты белән инженерлык мәктәпләре челтәрен булдыру. «Инженерлык республикасы» мәгариф проекты 2018 елның 1 сентябрендә

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ, Яшьләр инновацион иҗат үзәге, Speak English инглиз теле мәктәбе ярдәмендә старт алды. Проект Казан шәһәре Совет районының «Лицей – инженерлык үзәге» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе белән бергә алып барыла. Мәгариф проекты өстәмә белем бирү форматында заманча мәгариф технологияләрен кулланып, авторлык белем бирү программалары буенча техник һәм лингвистик юнәлешләрне берләштерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Шулай ук Татарстан Республикасында Казан шәһәрендә һәм Зеленодольск шәһәрендә «Судно төзелеше» һәм «Авиатөзелеш» профильләре буенча инженерлык сыйныфлары түбәндәге гомуми белем бирү оешмалары базасында ачылды:

Казан шәһәре Идел буе районының «35 нче лицей – «Галактика» мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба – МБГББУ) (авиатөзелеш);

Казан шәһәре Идел буе районының «83 нче лицей – Мәгариф үзәге» МБГББУ (авиатөзелеш);

Казан шәһәре Яңа Савиново районының «179 нчы гимназия – Мәгариф үзәге» МБГББУ (авиатөзелеш);

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее» МБГББУ (суднолар төзелеше);

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 3 нче гимназиясе» МБГББУ (суднолар төзелеше);

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 4 нче УГББМ» МБГББУ (суднолар төзелеше);

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «14 нче лицей» МБГББУ (суднолар төзелеше);

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының М.В.Ломоносов исемендәге 18 нче күппрофильле лицей» МБГББУ (суднолар төзелеше).

Казан шәһәре Идел буе районының «35 нче лицей – «Галактика» мәгариф үзәге» МБГББУ, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 3 нче гимназиясе» МБГББУ шулай ук белем бирү сыйфатын арттыру һәм мәктәп белеме өлкәсендә фәнни-технологик инновацион үсешне тәэмин итү бурычлары белән берләштерелгән Мәктәп инженерлык-технологик белем бирүне үстерү консорциумына – төрле дәрәҗәдәге мәгариф оешмаларының ирекле берләшмәсенә керә.

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында 2019 елда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Малышев исемендәге Столбище урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ базасында «Үсеш ноктасы» үзәге булдырылды; 2022 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «2 нче лицей» МБГББУ базасында «Кванториум» мәктәп технопаркы төзелде. Оешмаларда белем алучылар техник юнәлештәге төрле конкурсларда һәм ярышларда актив катнаша.

Яр Чаллы шәһәре мәктәпләре («30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ, «16 нчы мәгариф үзәге» урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ)

«Инженерлык мәктәбе» проектында катнашалар. Проект партнерлары – «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Яр Чаллы филиалы, «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Усады авылының «Сәламәт буын» күппрофильле лицее» МБГББУ лицейның гомуми белем бирү программасы кысаларында «Ясалма интеллект», «Инженерлык проектлавы» курсларын һәм махсус предметларын гамәлгә ашыра. Лицей «Уңыш – Успех» республика программасына кертелде.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Малышев исемендәге Столбище урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ инженерлык сыйныфлары бар.

Шулай ук проектка «Карпов Павел Алексеевич исемендәге Болгар кадет мәктәп-интернаты» һәм «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре кертелде, аларда пилотсыз очу аппаратлары белән идарә итү күнекмәләренә ия булачак хәрби хезмәткәрләрне әзерләү максаты белән махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) булдыру планлаштырыла.

«Лаеш техник-икътисадый техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Лаеш техникумы) 2021 елдан пилотсыз авиация системалары операторларын әзерли торган төбәкнең беренче уку йорты булды.

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектының «Үз илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллау» федераль проекты кысаларында Лаеш техникумы базасында пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем бирү процессларын гамәлгә ашыру өчен гамәли әзерләү үзәген төзү планлаштырыла. Техникумны сайлауга түбәндәгеләр нигез булды.

2020 елдан бирле Лаеш техникумы «Пилотсыз һава судноларын тышкы пилотлаштыру һәм эксплуатацияләү» компетенциясе буенча махсуслаштырылган үзәк статусына ия. 2021 елдан «Пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү» дигән яңа белгечлек лицензияләнде. «Мәгариф» илкүләм проектының «Яшь профессионаллар» федераль проекты кысаларында пилотсыз һава судноларын тышкы пилотлаштыру һәм эксплуатацияләү остаханәсе ачылды.

«Россия – мөмкинлекләр иле» коммерциягә карамаган автоном оешмасы проекты кысаларында Лаеш техникумы «Пилотсыз һава судноларын тышкы пилотлаштыру һәм эксплуатацияләү» компетенциясе буенча инвалидлар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» чемпионатын үткәрү буенча төбәк мәйданчыгы булып тора.

Лаеш техникумында эшчеләрнең квалификациясен күтәрү һәм аларны һөнәри яңадан әзерләү буенча өстәмә һөнәри программалар эшләнде һәм гамәлгә ашырыла. 2023 ел ахырына техникумда, «Пилотсыз авиация системалары операторы» квалификациясе бирелеп, 100 дән артык кеше, шул исәптән Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү

министрлыгының структур бүлекчәләре хезмәткәрләре укытылды. Россия Федерациясе Оборона министрлыгы өчен «Пилотсыз һава судноларын тышкы пилотлаштыру һәм эксплуатацияләү» юнәлеше буенча 374 хәрби хезмәткә өйрәтелде.

Укучылар пилотсыз очу аппаратлары белән зур кызыксына.

Әйтик, 2023 елның җәендә Новосибирск шәһәрендә «Архипелаг 2023» проект-белем бирү интенсивы кысаларында пилотсыз авиация буенча милли ярышлар узды. Татарстан Республикасы җыелма командасында 14 укучы һәм студент катнашты. Ярышлар нәтиҗәләре буенча укучылар 22 дисциплина буенча 13 алтын, тугыз көмеш, җиде бронза медаль яулады. Казан шәһәренең Идел буе районы «6 нчы гимназия» МБГББУнең сигезенче сыйныф укучысы Булат Нургалиев пилотсыз авиация буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән иң яшь оператор булды.

2021/2022 еллар чемпионат циклында Татарстан Республикасының «Яшь профессионаллар» төбәк чемпионатында Лаеш техникумы командасы беренче урынны яулады, ә Милли чемпионатның йомгаклау чемпионатында «Пилотсыз һава судноларын тышкы пилотлаштыру һәм эксплуатацияләү» компетенциясе буенча команда көмеш медаль алды.

«Армия-2023» халыкара хәрби-техник форумында техникум студентлары яшь армиячеләр өчен пилотсыз очу аппаратлары буенча конкурсны оештыручы буларак катнашты.

2023 елның көзеннән, «НОВОГЕН» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән берлектә, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы ихтыяҗлары өчен пилотсыз авиация системалары тармагына кадрлар ихтыяҗын бетерү максаты белән пилотсыз очу аппаратлары эшләнмәләре җыю оештырылды.

Иннополис шәһәрендә, Россия Федерациясенең инновацион шәһәрендә, пилотсыз очу аппаратлары юнәлеше актив үсә. Бу Иннополис илдә технологияләр һәм инновацияләр үсешенең төп үзәкләренең берсе булуы белән аңлатыла.

Шәһәрдә пилотсыз авиация системаларын эшләү һәм җитештерү, шулай ук пилотсыз аппаратлар белән идарә итү өчен программа тәэмин итү буенча махсуслашкан компанияләр эшли. Менә аларның кайберләре:

Innopolis Aviation – пилотсыз авиация системаларын эшләү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче компания;

AeroDrones – пилотсыз очу аппаратлары белән идарә итү өчен программа тәэминатын эшләү буенча махсуслашкан компания;

Volocopter – мультикоптерлар җитештерүче һәм алар өчен программа тәэминатын эшләүче немец компаниясе.

Иннополис шәһәре бөтен дөньядан инвестицияләр һәм белгечләр җәлеп итә, бу пилотсыз очу аппаратлары тармагын үстерүгә һәм яңа инновацион продуктлар булдыруга ярдәм итә. Шәһәрдә пилотсыз технологияләрне үстерү мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләр һәм семинарлар уздырыла.

Моннан тыш, Иннополис Н.Э.Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техник университеты һәм А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ кебек башка фәнни һәм мәгариф үзәкләре белән актив хезмәттәшлек итә.

«Иннополис» махсус икътисадый зонасы һәм Иннополис университеты

«Пилотсыз авиация системалары» җәмгыяте белән килешүгә кул куйдылар.

2023 елның гыйнварында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, очу дроннары белән йөк ташуны сынау өчен эксперименталь хокукый режим кертү турында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең мөрәҗәгатен хуплап, карар кабул итте.

2024 елда Иннополис шәһәрендә беренче тапкыр шәһәр чигендә эксперименталь хокукый режим кысаларында оча торган дроннар белән әйбер алып баруны сынап карыйлар, аны 2023 ел башында эшләтеп җибәрделәр. Бу шәһәр аэромобильлеге буенча эксперименталь хокукый режимның беренче программасы. Хәзер Иннополис шәһәрендә пилотсыз очкычларның барлык типлары файдаланылачак: җир өсте буенча тәэмин итүчеләр, автоном роботакслар һәм дроннар белән аэрокитерү.

Иннополис шәһәренең мәгариф оешмалары, шул исәптән Иннополис мәктәбе дә, пилотсыз очу аппаратлары өлкәсен уңышлы үстереп, читтә калмый. Бу хакта укучыларның робототехника буенча төрле ярышларда, шул исәптән пилотсыз очу аппаратлары белән, спорт программалаштыруы буенча, шулай ук технология һәм информатика буенча бөтенроссия олимпиадаларында нәтиҗәләре дәлилли.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 март, 125 нче
карары белән расланды

2024 елда пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазлар белән җиһазландыру буенча чаралар комплексы («юл картасы»)

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы | Нәтиҗәсе | Башкару срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) һәм практик әзерләү үзәкләре өчен җиһазлар исемлеге формалаштырылды һәм килештерелде | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (яисә вәкаләтле оешманың) хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы | 2024 елның марты |
| 2. | Махсуслаштырылган сыйныфларның (түгәрәкләрнең) һәм практик әзерләү үзәкләренең дизайн-проектлары килештерелде һәм расланды | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (яисә вәкаләтле оешманың) хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы | 2024 елның марты |
| 3. | Махсуслаштырылган сыйныфларны (түгәрәкләрне) һәм практик әзерләү үзәкләрен җиһазлау өчен җиһазлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планы формалаштырылды | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының боеру характерындагы акты | 2024 елның марты |
| 4. | Махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) һәм практик әзерләү үзәкләрен булдыру өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу игълан ителде | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | сатып алуларны үткәрү турында хәбәрнамәләр | 2024 елның марты – апреле |
| 5. | Махсуслаштырылган сыйныфлар (түгәрәкләр) һәм практик әзерләү үзәкләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен квалификацияле педагогик кадрлар укыту һәм әзерләү чаралары кысаларында педагогик | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | уку узу турында документлар; педагогик хезмәткәрләрне укыту буенча хисап | аерым график буенча |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәткәрләрне укыту | | | |
| 6. | Ремонт эшләре башкарылды | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль берәмлекләр | башкарылган эшләр акты | 2024 елның 1 маена кадәр |
| 7. | Махсуслаштырылган сыйныф-ларны (түгәрәкләрне) яисә практик әзерләү үзәкләрен җиһазлау төгәлләнде (җиһазлар китерелде, урнаштырылды һәм файдалануга тапшырылды) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | эшләрне кабул итү актлары, товар накладнойлары | 2024 елның 1 июненә кадәр |
| 8. | Махсуслаштырылган сыйныф-ларны (түгәрәкләрне) һәм практик әзерләү үзәкләрен ачу | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту | 2024 елның 1 июленә кадәр |
| 9. | Махсуслаштырылган сыйныф-ларны (түгәрәкләрне) һәм практик әзерләү үзәкләрен җиһазлан-дыруга мониторинг үткәрелде | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | форма буенча хисап, шул исәптән фотохисап | 2024 елның 1 июленә кадәр |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 март, 125 нче
карары белән расланды

2024 елда пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белем бирү барышларын гамәлгә ашыру өчен инфраструктурасын җиһазлар белән җиһазландыру планлаштырыла торган төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары исемлеге

| Т/с | Россия Федерациясе субъекты исеме | Торак пункт исеме | Мәгариф оешмасының исеме (устав буенча) | Юридик затның адресы | Җиһазландырыла торган мәгариф оешмасының (филиалның) адресы | Мәгариф оешмасы ИННы | Мәгариф оешмасы КППы | Укучылар саны, кеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Татарстан Республикасы | Казан шәһәре | Казан шәһәре Идел буе районының «35 нче лицей – «Галактика» мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба – МБГББУ) | 420064, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гариф Ахунов ур., 10А й. | 420064, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гариф Ахунов ур., 10А й. | 1659125701 | 165901001 | 4 729 |
| 2. | Татарстан Республикасы | Казан шәһәре | Казан шәһәре Идел буе районының «83 нче лицей – Мәгариф үзәге» МБГББУ | 420110, Татарстан Республикасы, Казан ш., Бертуган Касыймов ур., 52 й. | 420110, Татарстан Республикасы, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., 52 й. | 1659027327 | 165901001 | 2 728 |
| 3. | Татарстан Республикасы | Казан шәһәре | Казан шәһәре Яңа Савиново районының «179 нчы гимназия – Мәгариф үзәге» МБГББУ | 420066, Татарстан Республикасы, Казан ш., Әбсәләмов ур., 29А й. | 420066, Татарстан Республикасы, Казан ш., Әбсәләмов ур., 29А й. | 1657199585 | 165701001 | 2 078 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Татарстан Республикасы | Казан шәһәре | Казан шәһәре Идел буе районының «6 нчы гимназия» МБГББУ | 420138, Татарстан Республикасы, Казан ш., Юлиус Фучик ур., 26 й. | 420138, Татарстан Республикасы, Казан ш., Юлиус Фучик ур., 26 й. | 1659026732 | 165901001 | 2 226 |
| 5. | Татарстан Республикасы | Казан шәһәре | Казан шәһәре Совет районының «Лицей – инженерлык үзәге» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе | 420073, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 114 й. | 420073, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 114 й. | 1660284304 | 166001001 | 454 |
| 6. | Татарстан Республикасы | Зеленодольск шәһәре | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее» МБГББУ | 422550, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре, Юность ур., 3 й. | 422550, Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре, Юность ур., 3 й. | 1648004543 | 164801001 | 1 086 |
| 7. | Татарстан Республикасы | Зеленодольск шәһәре | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 3 нче гимназиясе» МБГББУ | 422540, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Космонавтлар ур., 13 й. | 422540, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Космонавтлар ур., 13 й. | 1648004751 | 164801001 | 1 051 |
| 8. | Татарстан Республикасы | Зеленодольск шәһәре | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | 422544, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Украина ур., 4 й. | 422544, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Украина ур., 4 й. | 1648007600 | 164801001 | 764 |
| 9. | Татарстан Республикасы | Зеленодольск шәһәре | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «14 нче лицей» МБГББУ | 422544, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Тургенев ур., 19 й. | 422544, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Тургенев ур., 19 й. | 1648006999 | 164801001 | 933 |
| 10. | Татарстан Республикасы | Зеленодольск шәһәре | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының М.В.Ломоносов исемендәге 18 нче күппрофильле лицее» МБГГБУ | 422545, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Комаров ур., 45 й. | 422545, Татарстан Республикасы, Зеленодольск ш., Комаров ур., 45 й. | 1673002130 | 167301001 | 1 356 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Татарстан Респуб-ликасы | Иннопо-лис шәһәре | «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе | 420500, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Инно-полис ш., Парк ур., 22 й. | 420500, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Инно-полис ш., Парк ур., 22 й. | 1615012965 | 161501001 | 696 |
| 12. | Татарстан Респуб-ликасы | Бөгелмә шәһәре | Татарстан Республикасы Бө-гелмә муниципаль районы-ның «2 нче лицей» МБГББУ | 423230, Татарстан Республикасы, Бө-гелмә ш., Николай Гоголь ур., 64 й. | 423230, Татарстан Республикасы, Бө-гелмә ш., Николай Гоголь ур., 64 й. | 1645010443 | 164501001 | 1 250 |
| 13. | Татарстан Респуб-ликасы | Болгар шәһәре | «Карпов Павел Алексеевич исемендәге Болгар кадет мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 422840, Татарстан Республикасы, Болгар ш., Совет ур., 15 й. | 422840, Татарстан Республикасы, Болгар ш., Совет ур., 15 й. | 1637006059 | 163701001 | 110 |
| 14. | Татарстан Респуб-ликасы | Казан шәһәре | «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктә-бе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 420012, Татарстан Республикасы, Казан ш., Катановский тыкрыгы ур., 1 й. | 420012, Татарстан Республикасы, Казан ш., Катановский тыкрыгы ур., 1 й. | 1654011690 | 165501001 | 403 |
| 15. | Татарстан Респуб-ликасы | Усад авылы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районын-дагы Усад авылының «Сәламәт буын» күппро-фильле лицее» МБГББУ | 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Усад авылы, Габдулла Тукай ур., 9 й. | 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Усад авылы, Габдулла Тукай ур., 9 й. | 1624019156 | 162401001 | 1 014 |
| 16. | Татарстан Респуб-ликасы | Столбище авылы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-ның «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Малышев исемендәге Столбище урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище ур., Мәктәп ур., 10 й. | 422624, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище ур., Мәктәп ур., 10 й. | 1624003540 | 162401001 | 1 173 |
| 17. | Татарстан Респуб- | Яр Чаллы шәһәре | «30 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | 423838, Татарстан Республикасы, Яр | 423838, Татарстан Республикасы, Яр | 1650329443 | 165001001 | 1 611 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ликасы | | | Чаллы ш., Илдар Маннанов исемендәге ур., 12 й. | Чаллы ш., Илдар Маннанов исемендәге ур., 12 й. | | | |
| 18. | Татарстан Республикасы | Яр Чаллы шәһәре | «16 нчы мәгариф үзәге» урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | 423838, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы ш., Раскольников ур., 4 нче бина | 423838, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы ш., Раскольников ур., 4 нче бина | 1650425884 | 165001001 | 720 |
| 19. | Татарстан Республикасы | Лаеш шәһәре | «Лаеш техника-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш ш., Маяковский ур., 14 й. | 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш ш., Маяковский ур., 14 й. | 1624001166 | 162401001 | 565 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 6 март, 125 нче
карары белән расланды

Төп гомуми белем бирү программаларын (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын җиһазландыру чараларын башкару нәтиҗәлелегенең
максатчан күрсәткечләре

| Т/с | Максатчан күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2024 елга күрсәткечнең планлаштырыла торган зурлыгы |
|---|---|---|---|
| 1. | Пилотсыз авиация системалары өлкәсендә төп гомуми белем бирү программалары (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), өстәмә белем бирүнең мәгариф программалары һәм урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары (шул исәптән электрон белем бирү һәм (яки) дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып) гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмалары саны (арта бара торган йомгак белән) | берәмлек | 19 |
| 2. | Пилотсыз авиация системалары өлкәсендә өстәмә белем бирүнең мәгариф программалары һәм урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары (шул исәптән электрон белем бирү һәм (яки) дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып) буенча белем алучылар саны (арта бара торган йомгак белән) | кеше | 560 |
| 3. | Квалификацияле педагогик кадрларны укыту һәм әзерләү чаралары кысаларында төп гомуми белем бирү программалары (мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларыннан тыш), өстәмә белем бирүнең мәгариф программалары һәм урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмалары өчен укытылган педагогик хезмәткәрләр саны (тупланып бара торган йомгак белән) | кеше | 84 |
| 4. | Цифрлы белем бирү контентыннан файдаланып, пилотсыз авиация системаларын проектлау, эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү күнекмәләрен өйрәтү модульләре кертелгән, гамәлгә ашырыла торган урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары, өстәмә белем бирү программалары саны (тупланып бара торган йомгак белән) | берәмлек | 23 |

________________________